**ПРОЕКТ**

# Төп гомуми белем бирү программалары буенча төп дәүләт имтиханы (ТДИ) формасындагы дәүләт йомгаклау аттестациясе

# ГЕОГРАФИЯ буенча 2016 нчы елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының демонстрацион варианты

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе
тарафыннан әзерләнгән

# ГЕОГРАФИЯ буенча 2016 нчы елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының (КҮМ) демонстрацион варианты

## Имтихан эшенең демонстрацион вариантына аңлатма

2016 нчы елгы демонстрацион вариант белән танышканда, әлеге вариантка кертелгән биремнәрнең 2016 нчы елгы КҮМның вариантлары тарафыннан тикшереләчәк эчтәлекнең бөтен элементларын да чагылдырмауларын исәпкә алырга кирәк. 2016 нчы елгы имтиханда контрольгә алынырга мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә куелган эчтәлек һәм таләпләр элементларының www.fipi.ru. сайтында урнаштырылган Кодификаторында китерелә.

Демонстрацион вариант имтиханда катнашучылар һәм киң катлам җәмәгатьчелек имтихан эшенең структурасы һәм биремнәрнең саны, формасы, аларның катлаулылык дәрәҗәләре турында күзаллау барлыкка китерә алсын өчен бирелә. Имтихан эшенең демонстрацион вариантына кертелгән киңәйтелгән җавап таләп итә торган биремнәрне бәяләү өчен китерелгән критерийлар киңәйтелгән җавапны тулы һәм дөрес төзүгә таләпләр турында күзаллау барлыкка китерергә мөмкинлек бирәләр.

Бу мәгълүматлар чыгарылыш сыйныф укучысына география буенча имтиханга әзерләнүнең стратегиясен төзергә мөмкинлек тудыра.

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**2016 нчы елгы демонстрацион вариант**

**Эшне башкару буенча Инструкция**

Имтихан эше 30 биремнән тора. Географиия буенча эшне башкару өчен 2 сәгать вакыт (120 минут) бирелә.

Имтихан эше җавап булып килергә мөмкин булган вариантлары китерелгән 17 биремне үз эченә ала. Мондый биремнәргә җавап дөрес җавапның номерына туры килә торган бер цифр белән языла. Бу цифрны эшнең текстындагы җаваплар кырына языгыз.

Имтихан эшенә җавабын сүз яки сүзтезмә буларак язуны таләп итә торган 3 бирем һәм җавабын сан яки цифрлар эзлеклелеге белән язуны таләп итә торган 7 бирем кертелгән. Бу биремнәрнең җавабы имтихан эшенең җавап өчен бирелгән урынында языла.

Җавабыгызны дөрес язмаган очракта, аны сызыгыз һәм янәшәсендә яңасын языгыз.

Имтихан эше тулы киңәйтелгән җавап таләп итә торган 3 биремне (15, 20 и 23) үз эченә ала. Бу биремнәргә җаваплар аерым биттә яки бланкта языла. Башта биремнең номерын, аннан соң аның җавабын языгыз

Эшне башкарганда 7, 8 һәм 9 нчы сыйныф географик атласларыннан, линейка һәм программалаштырылмаган калькуляторлардан файдаланырга рөхсәт ителә.

Эшне башта караламаларда башкарырга мөмкин. Караламадагы язмалар эшне бәяләгәндә исәпкә алынмыйлар.

Биремнәрне үтәү өчен куелган баллар бергә кушылалар. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәрне үтәргә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

***Уңышлар телибез!***

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**1** Түбәндә санап кителгән кайсы илнең территориясендә мәйданы ягыннан Җир йөзендәге иң зур иңкүлек урнашкан?

1) АКШ
2) Кытай
3) Бразилия
4) Канада

Җавап: ☐

**2** Түбәндә санап кителгән илләрнең кайсы белән Россиянең коры җир һәм диңгез чикләре бар?

1) Эстония
2) Белоруссия
3) Монголия
4) Япония

Җавап ☐

**3** Россиянең уртача пояс климатында урнашкан кайсы территориясе өчен кискен континенталь климат характерлы?

1) АКШ
2) Кытай
3) Бразилия
4) Канада

Җавап: ☐

**4** Кар ишелмәләре – иң куркыныч табигать күренешләренең берсе. Россиянең санап кителгән кайсы регионында кар ишелмәсе аеруча зур куркыныч тудыра торган табигый күренеш булып тора?

1) Калининград өлкәсе
2) Төньяк Осетия – Алания Республикасы
3) Чуваш Республикасы
4) Архангельск өлкәсе

Җавап: ☐

**5** Россиянең санап кителгән регионнарының кайсында күмер чыгару промышленносте хуҗалыкның төп тармакларының берсе булып санала?

1) Краснодар крае
2) Кемерово өлкәсе
3) Астрахань өлкәсе
4) Карелия Республикасы

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**6** Биолог галимнәр сарыкүгезләр, ак аюлар, кайсыбер төр кошлар популяциясе бара торган урыннарны тикшерергә тиешләр. Аларга тикшеренү эшләре алып бару өчен түбәндә китерелгән тыюлыкларның кайсыларында булырга кирәк?

1) Врангель утравы
2) Магадан
3) Командорск
4) Печоро-Илычск

Җавап: 

**7** Россиянең түбәндә санап үтелгән регионнарының кайсында халыкның уртача тыгызлыгы иң югары?

1) Камчатка крае
2) Ростав өлкәсе
3) Мурманск өлкәсе
4) Карелия Республикасы

Җавап: 

***8, 9 биремнәр түбәндә китерелгән график нигезендә башкарыла.***




© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**8** Кайсы елны Россиягә башка илләрдән даими яшәү урынына күчеп килүче кешеләрнең иң аз санлы булуы күзәтелә?




**10** Санап кителгән, картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсылары антициклон зонасында?

1) Архангельск
2) Салехард
3) Ростов-Дон
4) Мәскәү

Җавап: ☐

**11** Әлеге һава торышы картасы 2013 нче елның 12 апреленә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый гына суытып җибәрү ихтималы зур?

1) Пермь
2) Сыктывкар
3) Омск
4) Төмән

Җавап: ☐

**12** Елга суларын пычранудан саклауга ярдәм итә

1) Елга үзәнлекләрендә урманнарны кисү
2) Елга ярларында сулыклар белән бәйле производствоны урнаштыру
3) Елганың үрге (баш) өлешендә сазлыкларны киптерү
4) Елга бассейннарында ашламалар куллануны чикләү

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**13** Түбәндә китерелгән фикерләрнең кайсында Башкортстан Республикасында халыкны кабат үсеш алуы турында мәгълүмат бирелә?

1) 2011 елның 1 январенә Башкортстан Республикасы халкының гомуми санының якынча 40% ын авыл халкы тәшкил итә
2) 2011 елның январе – сентябрендә Башкортстан Республикасыннан күчеп китүчеләр саны 25,3 мең кеше, ә Башкортостан Республикасына даими яшәү урынына күчеп килүчеләр саны – 21,5 мең кеше
3) 2011 елның январь – сентябрь айларында Башкортстан Республикасында 41 708 кеше туган, 41 401 кеше үлгән
4) 2011 елның 1 январенә Башкортстан Республикасында халык саны 4066 мең кеше

Җавап: ☐

**14** Кайсы тау түбәсенең географик координатлары 46° с.ш. 7° в.д?

Җавап: ______________________________

***15 бирем түбәндә китерелгән тексттан файдаланып башкарыла***

2010 елның феврале азагында Тын океанда Чили яр буенда 55 километр тирәнлектә Консепсьон шәһәреннән 115 километрга төньякта, 8,8 магнитудалы көчле җир тетрәү була. Җир тетрәү һәм аның артыннан килгән цунами нәтиҗәсендә 500 дән артык кеше һәлак була. Бер ел чамасы үткәч, 2011 нче елның 1 мартында Чилида 5,2 магнитудалы җиртетрәү теркәлә. Җир тетрәүнең эпицентрының Икике шәһәреннән 116 чакрымга көнчыгыштарак булуы күзәтелә. Аның учагы 99 километр тирәнлектә урнашкан була. Корбаннар һәм җимерелүләр турында мәгълүматлар бирелми.

**15** Ни өчен Чилидә җир тетрәүләр еш күзәтелә?
Җавапларыгызны аерым битләрдә яки бланкларда языгыз, башта биремнең номерын күрсәтегез

**16** «2011 елда РФ сендә авыл хуҗалыгы продукциясе» дип аталган таблицаның мәгълүматларын файдаланып, авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләмендә үсемлекчелек игенчелек продукциясенең өлешен (% ларда) билгеләгез. Алынган нәтиҗәне тулы санга кадәр түгәрәкләгез.

**2011 елда РФ сендә авыл хуҗалыгы продукция**
(миллиард сумнар)

| | |
|---|---|
| Авыл хуҗалыгы продукциясе | 3261,7 |
| шул исәптән: | |
| үсемлекчелек | 1703,5 |
| терлекчелек | 1558,2 |

Җавап: ______________________________%

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**17** Түбәндә китерелгән шәһәрләрне аларда яшәүче халыкларның саны арту тәртибендә урнаштырыгыз. Таблицага саннарның әлеге эзлеклелеген урнаштырыгыз.

1) Липецк
2) Новосибирск
3) Псков

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

***18–21 биремнәр түбәндә китерелгән топографик карта фрагментыннан файдаланып эшләнә***




**18** Карта буенча чишмәдән чиркәүгә кадәр туры юлны билгеләгез. Үлчәүне шартлы билгеләрнең үзәкләре арасында үткәрегез. Алынган нәтиҗәләрне дистә метрларга кадәр түгәрәкләгез. Җавапны сан белән языгыз?

Җавап: ______________________________м.

**19** Карта буенча чишмәнең манарадан (башнядан) нинди юнәлештә урнашуын билгеләгез?

Җавап: ______________________________

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**20** Фермер җиләк-җимеш бакчасы үстерә башлау өчен урын сайлый. Аңа яз көне кары иртә эри, ә җәй көне кояшлырак булган участок кирәк. Әлеге җир шулай ук җыелган уңышны консерв заводына алып китү өчен дә уңайлы урынга урнашкан булырга тиеш. Картада 1, 2 һәм 3 ле цифрлары белән билгеләнгән участокларның кайсы югарыда әйтелгән таләпләргә җавап бирә? Җавабыгызны ике дәлил белән ныгытыгыз. Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, иң башта биремнең номерын бирегез.

**21** Рәсемдә төрле укучылар тарафыннан А – В линияләре буенча төзелгән картага нигезләнгән урын рельефының профиле вариантлары бирелгән. Профильләрнең кайсы дөрес төзелгән.




Җавап:

***22, 23 биремнәр түбәндә китерелгән текст нигезендә башкарыла.***

Сокольск агач эшкәртү комбинатында (Сокол ш. Вологодск өлкәсе) илебездә беренчеләрдән булып ябыштырылган брус җитештерү технологиясен үзләштерәләр. Заводның проект куәте – бер елга 100 000 м3 ябыштырылган агач. Бүгенге көндә ул ябыштырылган брус һәм балкалар җитештерү буенча (12 м га кадәр) Россиядәге иң эре предприятияләрнең берсе.

**22** Вологда өлкәсенең урнашу урынын ачыклау өчен Россиянең түбәндә санап кителгән кайсы география районнарының картасын сайлап алырга кирәк?

1) Европа Төньягы
2) Көнчыгыш Себер
3) Көнбатыш Себер
4) Урал

Җавап:

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**23** Вологода өлкәсе табигый ресурсларына хас нинди үзенчәлек ябыштырылган брус һәм балкалар җитештерә торган предприятияләрне чимал белән өзлексез тәэмин ителеп торылуына китерә? Җавабыгызны, башта биремнең номерын күрсәтеп, аерым битләрдә яки бланкларда языгыз

**24** Россия регионнарын анда яшәүчеләрнең Яңа елны каршылауларында күзәтелгән эзлеклелектә урнаштырыгыз. Регионнарның әлеге эзлеклелеген чагылдырган саннарны таблицага язып куегыз?

1) Карелия Республикасы
2) Свердловск өлкәсе
3) Байкал аръягы крае

Җавап:

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**25** Россиянең төрле регионнарындагы туристик фирмалар, үз регионнарына туристларны җәлеп итү өчен, реклама лозунглары (слоганнар) төзегәннәр. Реклама лозунглары һәм регионнар арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы һәр элементка икенче багандан туры килә торган элемент сайлагыз?

| Реклама лозунглары | Регионнар |
|---|---|
| А) Кабатланмас матурлыкка ия тау хәзинәсе булган Телецк күле яр буена рәхим итегез! | 1) Карелия Республикасы |
| Б) Россиянең урта полосасы хәзинәсе булып саналган милли парк Валдайга рәхим итегез! Ильмень күленең матурлыгы белән хозурланыгыз! | 2) Краснодар крае |
| | 3) Алтай Республикасы |
| | 4) Новгород өлкәсе |

Таблицага сайлаган цифрларны тәңгәл килгән хәрефләр астына язып куегыз

Җавап:

| А | Б |
|---|---|
| | |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**26** Экскурсия вакытында укучылар карьерның текә ярындагы тау токымнары ятмасының схематик рәсемен биргәннәр?




Тау токымнарының рәсемдә күрсәтелгән катламнарын еллары арту тәртибендә (иң яшеннән иң борынгысына кадәр) урнаштырыгыз. Тау токымнары катламнарын чагылдырган цифрларны таблицага дөрес эзлеклелектә языгыз.

1) известьташ
2) валунлы туфрак
3) кварцит

Җавап: | | | |

**27** Климатограмманы анализлагыз һәм картада климат характеристикасы климатограммада чагылышы пунктын белдергән хәрефне билгеләгез.




© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте




1) A 2) B 3) C 4) D

Җавап:

***28, 29 нчы биремнәр түбәндә китерелгән тексттан файдаланып башкарыла.***

Россиянең берничә торак пункты укучылары җирле метеостанцияләрдә алынган күпьеллык метеокүзәтүләр белән алмашканнар. Алар тарафыннан җыелган мәгълүматлар түбәндәге таблицада чагылыш тапкан:

| Күзәтү пункты | Күзәтү пунктның географик координатлары | Диңгез өсте тигезлеге биеклеге, | Һаваның уртача температурасы | | Атмосферадагы явым-төшемнәрнең бер елга уртача, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | июль | январь | |
| Сортавала | 61° с.ш. 30° в.д. | 17 | +16,4 | –9,8 | 570 |
| Вологда | 59° с.ш. 40° в.д. | 125 | +17,0 | –11,9 | 568 |
| Балахна | 57° с.ш. 44° в.д. | 63 | +19,0 | –11,6 | 542 |
| Уфа | 54° с.ш. 56° в.д. | 104 | +19,5 | –15,0 | 569 |

**28** Укучылар билгеле бер пункттагы климат үзенчәлеге белән аның географик урыны арасындагы бәйләнешне ачыклау өчен тупланган материалны анализлаганнар. Укучыларның һәрберсенең нәтиҗәләре төрлечә килеп чыккан. Укучыларның кайсысы тәкъдим ителгән мәгълүматлар нигезендә дөрес нәтиҗә ясаган.

1) Алина: «Көньяк-көнчыгышка барган саен атмосферадагы явым-төшемнәрнең күләме арта бара, шуңа бәйле рәвештә атмосферадагы явым-төшемнәренең уртача еллык күләме дә артыграк була”.

2) Сергей: «Көньяк-көнчыгышка барган саен һава температурасының уртача еллык амплитудасы зуррак була».

3) Георгий: «Төньяккарак барган саен, январь аендагы һава температурасы түбәнрәк».

4) Тамара: «Билгеле бер пункт диңгез өсте тигезлегеннән югарырак булган саен, анда июль салкынрак була”

Җавап:

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**29** Түбәндә санап үтелгән торак пунктларның кайсында 22 июньдә төш вакытында җирле кояш вакыты буенча кояш нурларының төшү почмагы иң кыска булыр?

1) Сортавала
2) Вологда
3) Балагда
4) Уфа

Җавап: ☐

**30** Бирелгән кыскача сурәтләүгә нигезләнеп, илне табыгыз

Югары үсешкә ирешкән әлеге ил дүрт эре һәм берничә мең вак утрауларга урнашкан. Аның табигатенең үзенчәлекле ягы булып, тауларның күплеге, җир тетрәүләр ихтималлылыгының югары булуы, вулканнарның активлыгы тора. Ил файдалы казылмаларга ярлы. Меридиональ юнәлештә сузылган булуы аркасында климатик шартлар бик төрле. Территориясенең 60% тан артыгы, нигездә, таулар, урманнар белән капланган. Халыкның урнашу тыгызлыгы 1 км2 га 100 кешедән артык.

Җавап: ___________________________

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

## География буенча имтихан эшен бәяләү системасы

1–14, 16–19, 21, 22, 24–30 биремнәрне дөрес башкарган өчен 1 балл куела.
Әгәр таләп ителгән бер – ике сүз, цифр яки цифрлар эзлеклелеге дөрес күрсәтелсә, бирем дөрес эшләнгән санала.

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 1 |
| 3 | 1 |
| 4 | 2 |
| 5 | 2 |
| 6 | 1 |
| 7 | 2 |
| 8 | 2 |
| 9 | 296 |
| 10 | 2 |
| 11 | 3 |
| 12 | 4 |
| 13 | 3 |
| 14 | Монблан |
| 16 | 52 |
| 17 | 312 |
| 18 | 410; 420; 430 |
| 19 | С; Төньяк; төньякта |
| 21 | 4 |
| 22 | 1 |
| 24 | 321 |
| 25 | 34 |
| 26 | 213 |
| 27 | 2 |
| 28 | 2 |
| 29 | 1 |
| 30 | Япония |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**Киңәйтелгән җаваплы биремнәрне башкаруны бәяләү критерие**

2010 елның февраль ахырында Тын океанда Чили яр буйларында, Консепсьон шәһәреннән 115 километр төняктарак 55 километр тирәнлектә 8,8 магнитудалы көчле җир тетрәү була. Җир тетрәү һәм аның артыннан килгән цунами нәтиҗәсендә 500 дән артык кеше һәлак була. Якынча бер елдан соң, 2011 елның 1 мартында Чилиның төньягында 5,2. магнитудалы җир тетрәү теркәлә. Җир тетрәүнең эпицентры Икике шәһәреннән 116 километр көнчыгыштарак урнашкан булып, учагы 99 километр тирәнлектә була. Корбаннар һәм җимерелүләр турында мәгълүматлар юк.

**15** Ни өчен Чилидә җир тетрәүләр еш була?
Башта биремнең номерын күрсәтеп, җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз?

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка төрле формулировка да булырга мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта еш күзәтелә торган җир тетрәүләр территориянең Җир шарының тышкы каты кабыгы (литосфера) плитәләре чигендә булуы белән аңлатыла.<br><u>Җавапларның үрнәкләре</u>:<br>• *Чили Җир шарының тышкы каты кабыгы (литосфера) плитәләрнең контакт зонасында урнашкан*<br>• *Монда Җир шарының ике тышкы каты кабыгы плитәсенең бәрелеше күзәтелә* | 2 |
| Җавапта еш күзәтелә торган җир тетрәүләр территориянең сейсмик пояста урнашуы, кайнозойск җыерчыклылыгы өлкәсендәге урыны, яки «Тын океан утлы боҗрасы» («Тихоокеанского огненного кольца») чикләрендә урнашуы белән аңлатыла.<br><u>Җавапларның үрнәкләре</u>:<br>• *Чили сейсмик пояста урнашкан. Шул кысаларда җир тетрәүләрнең учаклары барлыкка килергә мөмкин.*<br>• *Бу территория кайнозойск җыерчыклыгы өлкәсендә күзәтелә*<br>• *Чили территориясе җир тетрәүләр еш күзәтелә торган «Тын океан утлы боҗрасы» («Тихоокеанского огненного кольца») чикләрендә урнашкан* | 1 |
| Җавапта литосфера плитәләре турында да, территориянең сейсмик пояста урнашуы турында да, кайнозойск җыерчыклылыгы өлкәсендәге урыны, яки «Тын океан утлы боҗрасы» («Тихоокеанского огненного кольца») чикләрендә урнашуы турында да бернәрсә дә әйтелми.<br>**<u>Җавап үрнәкләре</u>:**<br>• *Чилида, Мексикада, Японииядә җир тетрәүләр еш була.* | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте




**20** Фермер җиләк-җимеш бакчасы үстерә башлау өчен урын сайлый. Аңа яз көне кары иртә эри, ә җәй көне кояшлырак булган участок кирәк. Әлеге җир шулай ук җыелган уңышны консерв заводына алып китү өчен дә уңайлы урынга урнашкан булырга тиеш. Картада 1, 2 һәм 3 ле цифрлары белән билгеләнгән участокларның кайсы югарыда әйтелгән таләпләргә җавап бирә? Җавабыгызны ике дәлил белән ныгытыгыз.
Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, иң башта биремнең номерын бирегез.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка төрле формулировка да булырга мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта барыннан да бигрәк **2 нче участокның** күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүе әйтелә**, һәм ике дәлил** китерелә, болар укучының картадан шоссены таба алуларын, төньяк һәм көньяк тау битләренең яктыртылулары аермасын аңлый һәм аларны картада билгели белүләрен күрсәтә.<br>Җавап үрнәкләре:<br>• *2нче участокны сайларга кирәк. Ул көньяк тау битендә шоссе белән янәшә урнашкан, аннан алмаларны шәһәргә илтергә уңай.* | 2 |
| Җавапта **2 нче участок** туры килүе хакында әйтелә һәм **бер дәлил** китерелә, әлеге нигезләмәдән күренгәнчә, укучы | 1 |

| | |
|---|---|
| картада шоссены таба ала яки төньяк яки көньяк экспозиция сөзәклегенең яктыртылуындагы аерманы аңлый һәм картада аларны билгели ала.<br>ЯКИ<br>Җавапта **3 нче яки 1 нче** җир участогының туры килү хакында әйтелә, **һәм бер дәлил** китерелә. Әлеге дәлил укучының төньяк яки көньяк экспозициянең яктыртылуындагы аерманы аңлый һәм картада аларны билгели ала.<br>Җавап үрнәкләре:<br>• *2 нче участок, чөнки ул юл белән янәшә урнашкан.*<br>• *2 нче участок, чөнки ул көньяк экспозиция сөзәклегендә урнашкан.*<br>• *3 нче участок, чөнки ул кояш яхшы җылыта һәм көнбатыш җилләрдән урман саклый торган сөзәклектә урнашкан.*<br>• *1 нче участок, чөнки ул шоссе белән янәшә урнашкан.* | |
| Җавапта 2 нче участок аталган, тик ул дәлилләнмәгән яки дәлил дөрес түгел.<br>ЯКИ<br>Җавапта теләсә кайсы участок аталган һәм укучының картада шоссены таба алуын **яки** төньяк һәм көньяк экспозициянең яктыртылуындагы аерманы аңлый һәм картада аларны билгели алуын күрсәтүче дәлил китерелә.<br>Җавап үрнәкләре:<br>• *Минем уйлавымча, 2 нче участок, чөнки ул яхшырак.*<br>• *1 нче участок яхшырак.*<br>• *1 нче участок башня янында, анда алмалар саклап була.* | |
| Максималь балл | 2 |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

Сокольск агач эшкәртү комбинатында (Сокол ш., Вологодск өлкәсе) илебездә беренчеләрдән булып ябыштырылган брус җитештерү технологиясен үзләштерәләр. Заводның проект куәте – бер елга 100 000 м3 ябыштырылган агач. Бүгенге көндә ул ябыштырылган брус һәм балкалар җитештерү буенча (12 м га кадәр) Россиядәге иң эре предприятиеләрнең берсе.

**23** Вологода өлкәсе табигый ресурсларына хас нинди үзенчәлек ябыштырылган брус һәм балкалар җитештерә торган предприятиеләрнең чимал белән өзлексез рәвештә тәэмин итеп торылышына китерә?
Җавабыгызны, башта биремнең номерын күрсәтеп, аерым битләрдә яки бланкларда языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка төрле формулировка да булырга мөмкин) | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта регионда урман ресурслары булу турында әйтелә.<br>Җавап үрнәкләре:<br>• *Бу производство Вологда өлкәсе тулысынча тәэмин ителгән урман ресурсларына юнәлдерелгән.*<br>• *Вологода өлкәсендә брус җитештерү өчен кирәк булган урманнар күп.* | 1 |
| Җавапта регионда урман ресурслары булу турында бер сүз дә әйтелми.<br>Җавап үрнәкләре:<br>• *Сайлауга монда әлеге продукциядән файдаланучы булу йогынты ясаган.*<br>• *Мондый предприятиеләрне урнаштыруга хезмәт факторы йогынты ясый.* | 0 |
| *Максималь балл* | 1 |

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестацияләве үткәрү тәртибе (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 25 декабрендәге 1394 номерлы боерыгы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2014 елның 3 февралендәге 31206 номерлы карары белән теркәлгән) нигезендә

«48. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә имтихан эшләре биремнәренә җавапларның һәркайсына баллар куя... Ике эксперт куйган баллар арасында җитди аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Балларда җитди аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен элек тикшергән экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргысы булып тора».

15, 20 биремнәрнең теләсә кайсын үтәгән өчен баллар аермасы 2 балл булса, *өченче эксперт шундый җитди аермага китергән биремнәрне генә тикшерә.*

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте